| | |
|---|---|
| СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ — КАРАР

18.09.2017 с. Верхний Услон №30-137

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., 20 ст. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 1 п. 1 п., Югары Ослан авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсьәләләр буенча җирле референдум уздыруның уртак инициативасын чыгарырга:

«2018 елда авыл җирлегенең җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчаларны юллау белән килешерсезме:

- Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү

ӘЙЕ ЮК".

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Совет Рәисе ,
Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Башлыгы М. Г. Зиатдинов